**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2021 елның 29 декабренән № 17-132

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-106 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясына, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарга, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021елның 30 сентябрендәге 14-106 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәнең 4 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Вәкаләтле органның карарларына, муниципаль җир контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

4.2. Вәкаләтле орган карарларына, муниципаль җир контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаятьләр бирү тәртибе кулланылмый.».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021елның 30 сентябрендәге 14-106 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәнең 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядәге кушымтага нигезләнеп бәян итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы башлыгы — В. М. Козлов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советының 2021елның 30
сентябрендәге 14-106 номерлы карары белән
расланган Татарстан Республикасы Яңа
Чишмә муниципаль районы территориясендә
муниципаль җир контроле турындагы
нигезләмәгә
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы
муниципаль районы
Советының 2021 елның 29 декабреннән 17-
132 нче номерлы карары редакциясендә)

Муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм аның максатчан төшенчәләре, муниципаль җир контроле өчен индикатив күрсәткечләр исемлеге

| Төп күрсәткечләр | Максатчан төшенчәләр |
|---|---|
| Җир законнарын ачыкланган бозулар арасыннан төзәтелгән хокук бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына планлы контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру планын үтәү проценты | 100% |
| Контроль (күзәтчелек) чаралар үткәргәндә муниципаль контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи затының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) нигезләнгән шикаятьләр проценты | 0% |
| Контроль чаралар нәтиҗәләренең бетерелгәннәренең проценты | 0% |
| Тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән контроль (күзәтчелек) чаралары проценты | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында суд карарлары проценты | 95% |
| Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә юкка чыгарылган карарларның муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми саныннан проценты | 0% |

Муниципаль җир контроленең индикатив күрсәткечләре исемлеге

1) хисап чорында үткәрелгән планлы тикшерү чаралары саны;
2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;
3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә

контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе нигезендә үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;

4) хисап чорында үткәрелгән үзара хезмәттәшлек белән контроль чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән контроль чараларның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү буенча контроль чаралар саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралар саны;

7) хисап чорында үткәрелгән профилактик чаралар саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;

9) хисап чорында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирелгән контроль чараларның саны;

10) хисап чорында карарлар кабул итү өчен вәкаләтле органнарга тапшырылган контроль чаралар саны;

11) хисап чорында тикшерү чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

12) тикшерү (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны (алар буенча прокуратура органнары хисап чорында килешүдән баш тарткан);

13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

14) хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән контроль объектларының һәр категориясе буенча хисап чоры ахырына исәпкә алынган объектларының саны;

15) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;

16) хисап чорында контроль чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында комитетның вәкаләтле вазыйфаи затларының, комитет инспекторларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъвалау турында контрольлек итүче затлар тарафыннан җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

18) контрольдә тотыла торган затлар тарафыннан суд тәртибендә күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында дәгъвалар саны;

19) муниципаль контрольне (күзәтчелекне) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) хисап чорында юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны